ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» март 2020 ел № 84

«Тарихи хәтер» федераль проекты кысаларында бурычларны үтәү өчен эшче төркем төзү турында

Россия Федерациясе Президентының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру турында» 2018 елның 9 маендагы 211 номерлы указын үтәүне тәэмин итү, «Тарихи хәтер» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында координацияләнгән гамәлләр оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Тарихи хәтер» федераль проекты кысаларында бурычларны үтәү өчен эшче төркем төзергә (1нче кушымта)
2. 2020 елга «Тарихи хәтер» федераль партия проектын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаралар планын расларга (2нче кушымта)
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча «Тарихи хәтер» федераль проектын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирү буенча җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы М.Н. Романованы билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
06 март 2020 ел № 84
карарына 1нче кушымта

## 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Тарихи хәтер» федераль проекты кысаларында бурычларны үтәү өчен эшче төркем составы

| | | |
|---|---|---|
| Эшче төркем рәисе | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | Гыйльметдинова Римма Ринатовна |
| Эшче төркем секретаре | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы | Романова Марина Николаевна |
| Эшче төркем әгъзалары: | «Бердәм Россия " партиясенең Әгерҗе җирле бүлекчәсе башкарма секретаре | Усманова Гүзәл Фидаиловна |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе | Рыкова Энҗе Рафисовна |
| | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Әгерҗе муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы | Зарипова Альмира Таһировна |
| | Россия Пенсия фондының Татарстан Республикасының Әгерҗе районындагы идарәсе башлыгы | Бакасова Зөлфия Шамилевна |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы | Гатауллин Марс Мөбәрәкович |
| | "Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе" МУП директоры вазыйфаларын башкаручы | Михайловский Григорий Александрович |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе | Бадахшин Альфред Нәвитович |
| | Территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләре | Безбородова Клара Васильевна<br>Соболева Светлана Анатольевна |
| | "Авангард" Яшьләр үзәге директоры | Шахмин М.Ф. |
| | «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясе директоры | Абзалиева Дания Зәңгировна |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге башлыгы | Сергеева Татьяна Сергеевна |
| | Авыл җирлекләре башлыклары | |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
06 март 2020 ел № 84
карарына 2нче кушымта

План мероприятий по реализации федерального проекта «Историческая память» на 2020 год
в Агрызском муниципальном районе Республики Татарстан

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары |
|---|---|---|---|
| 1 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы символикасы төшерелгән урам рекламасы урнаштыру | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |
| 2 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә торак пунктларны төзекләндерү һәм бәйрәмчә бизәү | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |
| 3 | Белем бирү учреждениеләре укучыларын җәлеп итеп, хәрби-патриотик, эзләнү һәм тикшеренү эшләрен оештыру | Архив бүлеге, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге | 2020 |
| 4 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган Татарстан Республикасында тантаналы чараларны оештыру һәм уздыру. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышының мөһим вакыйгаларына багышланган Россия Федерациясендә үткәрелә торган бәйрәм чараларында Татарстан Республикасында яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннарының катнашуын оештыру | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Әгерҗе муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе (килештерү буенча) | 2020 |
| | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы | Әгерҗе шәһәрендәге “Түбән Кама агросәнәгать | даими |

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары |
| --- | --- | --- | --- |
| 5 | ветераннарының торак шартларын тикшерү буенча студентлар рейдларын оештыру | көллияте" урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең 2 нче филиалы (килештерү буенча) | |
| 6 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларның мемориаль урыннарын һәм каберләрен тәртипкә китерү буенча мәктәп укучылары тарафыннан хезмәт десантын оештыру | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге, авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |
| 7 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә керә торган социаль характердагы сорауларның беренче чиратта үтәлешен оештыру | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге | 2020 |
| 8 | 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарына, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге | апрель 2020 |
| 9 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көне уңаеннан Татарстан Республикасы Президентының 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын тантаналы кабул итү мәҗлесендә муниципаль район ветераннарының катнашуы | Әгерҗе муниципаль районы Советы, ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Әгерҗе муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе (килештерү буенча) | 9 май, ел саен |
| 10 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм тыл хезмәтчәннәрен 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көне уңаеннан котлау | Район хәрби комиссары (килештерү буенча), Әгерҗе муниципаль районы Советы | 9 май, ел саен |
| 11 | "Үлемсез полк" халыкара акциясен оештыру һәм үткәрү | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 9 май, ел саен |

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары |
|---|---|---|---|
| 12 | Район торак пунктларында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлләргә веноклар салу | Әгерҗе муниципаль районы советы, авыл җирлекләре башкарма комитетлары | май, ел саен |
| 13 | Татарстан Республикасы торак пунктларындагы урамнарга һәм мәйданчыкларга, белем бирү учреждениеләренә, оешмаларга Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары – әлеге торак пунктларда туып-үскән кешеләр исемнәрен бирү | авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |
| 14 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына, Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройларына-муниципаль районда туып – үскән кешеләргә багышланган истәлек-мемориаль корылмалар мониторингын оештыру | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2020 |
| 15 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү чараларын оештыру: Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакытында һәлак булган сугышчылар ватанында элек билгеләнмәгән мемориаль такталар әзерләү һәм урнаштыру | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |
| 16 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына караган мемориаль корылмаларга (Советлар Союзы Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары, һәйкәлләр, обелисклар, стелалар, Мәңгелек утлар, истәлекле ташлар, мемориаллар, мемориаль комплекслар һ. б.) ремонт-торгызу эшләрен үткәрү, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә хәрби каберлекләрне тәртипкә китерү, шулай ук 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышы геройлары хөрмәтенә аталган урамнарны һәм мәйданнарны төзекләндерү. | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2020 |

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары |
|---|---|---|---|
| 17 | Активлык мәйданчыклары, яшьләр сәясәте оешмалары һәм учреждениеләре стендлары күргәзмәсендә катнашу | Архив бүлеге,Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге | 9 мая 2020 |
| 18 | “Безнең Җиңү” республика патриотик фотокроссында катнашу | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге | 2020 |
| 19 | “Безнең Җиңү” республика патриотик медиаконкурсында катнашу | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге | 2020 |
| 20 | «РТЮ» ААҖ филиалы – Горький тимер юлының Ижевск территориаль идарәсе җитәкчелегенең Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар-тимерьюлчылар белән тантаналы очрашуы | «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы-Горький тимер юлының Ижау бүлекчәсе (килештерү буенча) | апрель-май 2020 |
| 21 | Бөек Ватан сугышы ветераннарының хезмәт коллективлары һәм укучы яшьләр белән очрашуларын үткәрү, әлеге очрашуларның видеоязмасын оештыру өчен корпоратив коммуникацияләр хезмәтенә гаризалар әзерләү | «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы-Горький тимер юлының Ижау бүлекчәсе (килештерү буенча) | апрель-май 2020 |
| 22 | “Әгерҗе районы педагоглары- Бөек Ватан сугышында катнашучылар” хәтер дивары | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе | апрель 2020 |
| 23 | “Бөек Ватан сугышы" циклыннан кинохроника һәм сәнгать фильмнары күрсәтү | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | Март-май 2020 |
| 24 | Бөек Ватан сугышы балалары белән очрашу "Аларны сугыш тәрбияләде". (Тәбәрле авылы) | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | март 2020 |
| 25 | Җиңү паркында обелисклар янында өмәләр (авыл җирлекләре территорияләре) | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы оешмалары | 22.04.2020 |
| 26 | Бима авылы балалар өчен «Сказка о Мальчише-Кибальчише»- мультфильмын карау | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният | апрель 2020 |

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары |
|---|---|---|---|
| | | бүлеге | |
| 27 | "Әгерҗе" радиосында "Күңел чишмәләре" әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзаларының сугыш турында шигырьләренә күзәтү | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | апрель- май 2020 |
| 28 | Массакүләм мәгълүмат чараларында 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүдә тимер юл транспортының әһәмиятен, тимер юл гаскәрләренең, тимер юлчыларның сугыштан соңгы чорда тимер юлчыларның батырлыгын яктырту, ветераннарның иҗтимагый тормышында катнашуы һәм яшьләрне өлкән буынның иң яхшы традицияләрендә тәрбияләү | "ТАТМЕДИА" АҖ филиалы - «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясе, «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы – Горький тимер юлының Ижау бүлекчәсе (килештерү буенча) | 2020 |
| 29 | “Балаларга сугыш турында укыйбыз” акциясе | ПК «Ровесник» | май 2020 |
| 30 | “Үлемсез полк” акциясендә катнашу | ПК «Ровесник» | май 2020 |
| 31 | "Россия патриотларын үстерәбез. Яшибез һәм хәтерлибез” Бөтенроссия конкурсының республика этабында катнашу | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе | 2020 |
| 32 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган әдәби-патриотик әңгәмәләр-презентацияләр, хәтер сәгатьләре. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган китап-иллюстратив күргәзмәләр оештыру | Архив бүлеге, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе, район китапханәсе | 2020 |
| 33 | Китапханәләрдә Бөтенроссия “Балаларга сугыш турында укыйбыз” акциясе | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2020 |